**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Адав-Толымбай авылы гражданнары җыенының 2023елның 1 ноябрендәге 1 нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- коймалар төзү, төзекләндерү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (часовня территориясен төзекләндерү, кышкы чорда юлларны кардан чистарту).»

2. Җыен нәтиҗәләрен Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Әхмәтҗанов

Халык җыены секретаре Г.Ш. Насертдинова